**Г.Р. Мөгътәсимова, А.Д. Батталова**
**Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан**

# КЫТАЙ ТАТАРЛАРЫ ТЕЛЕНДӘГЕ РУС-ЕВРОПА АЛЫНМАЛАРЫНЫҢ ФОНЕТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

(Тикшеренүләр 11-04-00074 а/2011 (РГНФ) номерлы грант кысаларында башкарылды)

В данной статье рассматриваются особенности русско-европейских заимствований, характерных языку Китайских татар.

In given article features of the Russian-European loans, typical to language of the Chinese Tatars are considered.

Телнең сүзлек составы, үзенең фонетик һәм грамматик структурасына караганда, ачыграк система тәшкил итә. Тормыштагы яңалыкларны, яңа төшенчәләрне, предметларны атау кирәклеге алынмалар кабул итүгә китерә. Дөрес, бу очракта тел үз ресурсларын да файдалана ала. Тышкы тәэсирдән тыш, телнең үз эчендә дә төрле сәбәпләр булырга мөмкин. Мәсәлән, сирәк кулланыла торган сүзләр онытыла һәм чит элементлар белән алышына ала. Тискәре йогынты ясый торган омонимия күренеше вакытында алынма сүз кулланылышка керә. Синонимнар кирәк булу чит сүзләр алынуга китерә. Әлбәттә, соңгы очраклар телнең лексик составын баетуга китерми.

Телдә алынмалар барлыкка килүдә иҗтимагый факторлар да зур роль уйный: чит цивилизациягә сокланып карау, башка халыкларның җитештерү технологиясен үзләштерү, идарә итүче милләтнең буйсындырылган милләткә карата уздырган тел сәясәте һ. б.

Бу хезмәттә төп игътибар Шенҗаңда яшәүче татар диаспорасы вәкилләренең тел үзенчәлекләрен өйрәнүгә юнәлде, чөнки Кытайның нәкъ менә шул автоном районы татарларның көнчыгыш эмиграциясе үзәге булып санала. Кытай һәм татар чыганаклары дәлилләвенә караганда, Шенҗаңда татар сәүдәгәрләре һәм коммерсантлары XIX гасыр уртасында күренә башлый. Инде XIX гасыр ахырына Шенҗаңның барлык эре шәһәрләрендә татарларның сәүдә

итү урыннары була. Алар, сәүдә итүдән тыш, тире эшкәртү һәм тире иләп, мех эшләү белән шөгыльләнгәннәр.

2000 нче елгы рәсми статистик мәгълүматлар нигезендә хәзерге вакытта Кытайның Шенҗаң-Уйгыр автоном районында (СУАР) 4873 татар яши. Татар милли оешмалары исә 5,5 меңнән артык татар булуын билгеләп үтә. Алар Голҗа, Өремче һәм Чүгүчәк шәһәрләрендә гомер итәләр. Татарлар әлеге шәһәрләрдә үзләренең тарихи ватаннарындагы кебек үк мәдәни мохит тудырырга омтылганнар.

Татар мәдәниятен һәм телен сакларга омтылыш сизелерлек булса да, Кытайдагы татар эмигрантлары теләсәң дә теләмәсәң дә ассимиляция процессына катнашып китәләр. Алар даими рәвештә бер (үз, туган, татар) мәдәни һәм тел даирәсеннән башка (чит, бөтенләй ят, кытай) даирәгә күчү халәтендә яшәргә мәҗбүр. Татар телен белүнең кулай дәрәҗәсе (грамматик яктан дөреслек, сөйләү рәвеше, тел чараларын сайлау), теге яки бу дәрәҗәдә татар көнкүреше, мәдәни йолалары һәм әхлакый кыйммәтләрен саклау Кытайдагы татар диаспорасының өлкән буын вәкилләренә хас. Ә мәктәпләрдә, колледжларда һәм университетларда белем алучы яшь буын күбрәк кытай телендә аралаша һәм бик тиз туган телен онытa. Татар телен куллана торган төп урын – көнкүреш – үз этник диаспорасы вәкилләре белән гаиләдә сөйләшү һәм башка рәсми булмаган аралашулар. Татар этник төркеме эчендә, гаиләдә татар телендә аралашалар.

Шенҗаң татарлары телендә түбәндәге кызыклы күренешләрне билгеләп үтәргә кирәк: телнең нигезен татар лексемалары тәшкил итсә дә, гарәп-фарсы, рус-европа, уйгыр һәм кытай алынмалары да сөйләмдә кулланылуы билгеле булды. Алга таба без Кытай татарлары телендә кулланыла торган рус алынмаларына киңрәк тукталырбыз.

Кытай татарлары телендә дә рус-европа алынмалары билгеле бер урын алып тора. Тикшеренүләрдән соң шул билгеле булды: Шенҗанда яшәүче татар диаспорасы вәкилләренең телендә рус һәм Европа телләреннән алынган предметны, санын белдерә торган сүзләр шактый. Алар арасында предметны

белдергән сүзләр  күпчелекне тәшкил итә. Мәсәлән, **ышкап (шкаф), чашка, пуюз (поезд), тәрәктыр (трактор), аптобус (автобус), машина, пипинис (пепельница)** һәм башкалар.

Билгеле булганча, бер телнең аваз составы икенче телнең авазлар составы белән тулысынча тәңгәл килми. Хәтта кардәш телләр дә бер-берсеннән төрле-төрле фонетик үзенчәлекләр белән аерылып торалар. Шуңа күрә бер телдән икенчә телгә сүз кабул итү һәрвакыт төрле аваз үзгәрешләре белән бәйле була.

Кытайдагы татар диаспорасы вәкилләре телендә күзәтелгән рус-европа алынмаларының бер өлеше зур фонетик үзгәрешләргә дучар булган, ә кайберләре исә үзгәрешсез генә кулланыла. Кытай татарлары телендәге көнкүрешкә караган сүзләрнең фонетик үзгәрешсез кулланылуы характерлы: **машина, чашка, пар, вилка, сумка, папка, ваза, записка, журнал, кино, касса, роман, газ, фабрика** һәм башкалар.

Татар телендә сузыклар гармониясе законы алынма сүзләргә дә кагыла. Бу законга буйсынып, алар я калын, я нечкә сүзгә әйләнәләр. Рус-европа алынмалары арасында катнаш иҗекле сүзләр аз очрый. Өстәвенә алар соңрак кабул ителгән алынмаларга карый. Алга таба рус теленең аерым сузык фонемаларының субститутларын карап үтәрбез.

Рус теленең ачык әйтелә торган [а] фонемасы [**ә**] сузыгына күчә: газета – **гәзит**, капуста **– кәбестә,** скрипка — **скрипкә.**

Рус [о] сузыгы Кытай татарлары телендәге алынмаларда татар теленең [**у**] сузыгы белән субститутлаша: поезд – **пуюз**, лампочка – **лампушка**, паспорт – **паспурт**, поднос – **пәтмус**, тормоз – **турмус**, футбол – п**утбул**, термос – **термус**, директор – **директур**, магистор – **магистур,** хор **– хур**, ток – **тук,** опера **– упира,** поп **- пуп**, лимон — **лимун**, порошок — **парашук**, Россия — **Русия**, вагон — **вагун**, соха — **сука**, гармонь — **гармун,** помело — **пумала**, лом — **лум** һәм башкалар. Кайбер очракларда рус **[о]** авазы **[а]** авазына күчә: комбайн – **камбайн**, кислота – **кислата**, носки – **наски**, ботинка – **батинка**, число – **числа**, самовар – **самавар**, пиво – **пива**, компот – **кампат,** Москва – **Масква,** солома — **саман**, корабль — **караб** һәм башкалар. Рус теленнән кабул ителгән

сүзләрдәге [о] фонемасының [ә] фонемасына субститутлашуы да күзәтелде: помидор – **пәмидур**, конфета – **кәнфит**, **кәнпит**, солярка – **сәләрке,** офицер — **әфисәр**, конфета — **кәнпит**, һәм башкалар.

Гадәттә, рус [е] фонемасы татар телендә [и] сузыгына күчә. Мондый күренеш Кытай татарлары телендәге алынмалар арасында да очрый: телевизор – **тиливизор**, салфетка – **салфитка**, билет – **билит**, кассета – **касита**, ракета – **ракита**, телефон – **тилифон**, ресторан – **ристуран**, сетка – **ситкы**, лагерь – **лагир**, пенсия – **пинсия**, балет – **балит,** математика **– матиматика,** армия – **армия,** календарь **- калиндар** һәм башкалар.

Рус [и] фонемасы телдә бернинди үзгәрешләргә дучар булмыйча, шул килеш саклана: машина **– машина,** витамин – **витамин**, гитара – **гитар**, лифт – **лифт,** билет — **билет**, чистый — **чиста**, скрипач — **скрипкәче**, лимон — **лимун**, сухари — **сохари** һәм башкалар.

Кытайдагы татар диаспорасы вәкилләре телендә алынма сүзләрдә рус [у] фонемасы [о] авазы белән алышына: туфли – **тофли**, минус – **минос,** сухари **- сохари** һәм башкалар. Сирәгрәк очракта рус [у] авазы мәкальләрдә [ы] авазы белән алышына: хомут **- камыт**.

Шул рәвешчә, Кытай татарлары телендә күзәтелгән рус-европа алынмаларының сузык авазлары шактый үзгәрешләр кичереүе ачыкланды. Бигрәк тә рус [у], [е], [и], [о], [а] фонемалары татар теленең төрле сузык авазларына күчүе күп мисаллар белән расланды.

Күзәтелгән рус алынмаларында рус [в] фонемасы [ф] авазы белән субститутлашу очрагы теркәлде: автор – **афтор** һәм башкалар. Рус [в] фонемасының [п] авазы белән алмашынуына да мисаллар күзәтергә мөмкин: автобус – **аптобус**, булавка – **булапкы** һәм башкалар.

Рус-европа алынмалары арасында [ц] фонемасының Кытай татарлары телендә [с] фонемасы белән тәңгәлләшү очрагы да күзәтелә: цирк – **сирик** һәм башкалар.

Сүзләрдәге яңгырау тартыкларның саңгыраулашу күренеше дә очрый: велосипед – **вилиспит**, юбка – **юпка**, завод – **завот**, суд – **сут** һәм башкалар.

Шулай итеп, Кытай татарлары телендәге рус-европа алынмалары арасында тартыклар тәңгәллеге белән аерылып торган лексемалар да күзәтелде. Әлбәттә, алар сан ягыннан аз һәм сөйләм теленә карыйлар.

Сөйләм телендәге алынмаларның фонетик үзгәрешләре авазлар алмашынуга гына кайтып калмый. Алынма сүзләр комбинатор аваз үзгәрешләренә дучар булалар. Кытайдагы татар диаспорасы вәкилләре телендәге рус-европа алынмаларында да мондый аваз үзгәрешләренә шактый кызыклы мисаллар күзәтелде.

1) Рус-европа алынмаларында протеза яки сүз башына аваз өстәлү күренеше характерлы: шкаф – **ышкаф,** скрипка – **эскерипка,** стол — **өстәл** шляпа — **эшләпә**, рожь — **арыш**, рус — **урыс**, станция – **ыстансия**, склад – ысклад һәм башкалар.

2) Эпентеза яки алынма сүз уртасына аваз өстәлү татар теленә хас булмаган ике янәшә килгән тартыкны таркату өчен кулланыла. Мондый аваз үзгәрешләре Кытай татарлары телендә дә бар: трактор – **тәрәктор**, плюс – **пилус**, квас – **кавас**, грамматика – **гераматика**, труба – **туруба**, бензин – **бинизин**, президент – **персидинт,** кровать — **карават**, һәм башкалар.

3) Эпитеза — рус формасында булмаган сузык авазның телдәге сүз ахырына өстәлүе Кытай татарлары телендә еш булмаса да күзәтелә: банк – **банка**, танк – **танкы**, шарф – **шарпы** һәм башкалар.

4) Синкопа — рус сүзенең уртасындагы тартык авазның төшеп калуы да Кытайда яшәүче татарлар телендәге алынмаларда урын алган: тумбочка – **тумочка**, открытка – **аткирка** һәм башкалар.

5) Редукция — сүз уртасында сузык аваз төшеп калу да күзәтелә: велосипед – **вилиспит**, керосин – **керсин** һәм башкалар.

6) Апокопа — сүзнең кыскаруына китергән сүз ахырындагы басымсыз авазның төшеп калуы да Кытай татарлары телендәге рус алынмаларына хас: пепельница – **пипинис**, галоши – **калош**, газета – **гәзит**, аспирантура – **аспирантур**, гитара – **гитар**, бакалея — **бакали,** фонарь — **фанар,** минута —

**минут**, конфета — **кәнпит**, десяток — **дистә**, чистый — **чиста**, фабрика — ф**абрик**, больница — **бальнис** һәм башкалар.

Шулай итеп, Кытай татарлары телендә рус-европа алынмалары шактый фонетик үзгәрешләр кичергәннәр.

Әдәбият


1. Госманов М.Г. Ябылмаган китап. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1996. - 206 б.
2. Чанышев М. Кытайда татар мәгарифе тарихы. - Казан: “Җыен” нәшр., “Идел-пресс” нәшр., 2007. - 240 б.
3. Юсупова Ә.Ш., Мөгътәсимова Г.Р. Кытайдагы татар диаспорасы гаиләләрендә туган телнең урыны // Фәнни язмалар. – Казан: Вестфалика, 2011. - 272-274.
4. Юсупова Ә.Ш., Денмөхәммәтова Э.Н. Мәдәниятара бәйләнешләрдә кытай татарлары // Фәнни язмалар. – Казан: Вестфалика, 2011. - 269-272.